РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«02» сентябрь 2026 ел Олы Кайбыч ав. № 57

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2023 елның 30 гыйнварындагы 167 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларын һәм муниципаль хезмәткәрләрен бүләкләү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2023 елның 30 гыйнварындагы 167 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларын һәм муниципаль хезмәткәрләрен бүләкләү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3.3. пунктының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- муниципаль вазыйфа биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы затның, җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәренең айлык хезмәт хакы күләмен 20 проценттан артыкка киметүгә китерми торган күләмдә дисциплинар түләтүләр булган өчен;»;

- 3.5. пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе Р. Г. Айзатулловага йөкләргә.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль
районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин